Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение гимназия с. Раевский

| **СОГЛАСОВАНО** | **РАССМОТРЕНО** | **УТВЕРЖДАЮ** |
|---|---|---|
| на заседании ШМО учителей башкирского языка и татарского языка<br>Протокол №1<br>от «26» августа 2016г. | на заседании научно - методического совета<br>Протокол №1<br>от «29» августа 2016г. | Директор МБОУ гимназия с. Раевский<br>_________________Колеганов С. Н.<br>Приказ №<br>от «29» августа 2016г. |

# Рабочая программа

## по родному языку

## в 6В классе

Срок реализации: 2016-2017 учебный год

Составитель: учитель татарского языка и литературы Насырова Л.М.

Составлено на основе программы по татарскому языку и литературе («Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары»,Казан, «Мәгариф», 2010 )

2016г

## ЭЧТӘЛЕК


I. Аңлатма язуы.

II. Укыту предметына гомуми аңлатма.

III. Укыту предметының укыту планында тоткан урыны.

IV. Укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре.

V. Укыту предметының төп эчтәлеге.

VI. Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча  планлаштырылган нәтиҗәләре.

VII. Укыту предметының темаларга якынча бүленеше.

VIII. Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү.

## Аңлатма язуы

Эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелде:

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Башкортостан Республикасы Законы.
3. Гомуми белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы
4. ”Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары. 1-11 нче сыйныфлар”. – К., ,,Мәгариф” нәшрияты, 2010, 128б.

5.Раевка авылы гимназиясенең 2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планы

6. Дәреслек: Н.В.Максимов, М.З.Хәмидуллина ,,Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән басыла”. – К., ,,Мәгариф” нәшрияты, 2005, 192б.

6. Ярдәмлек: Н.В.Максимов, М.З.Хәмидуллина ,,Рус телендә белем бирүче мәктәптә ана теле укыту. 6 нчы сыйныф.(Укытучылар өчен методик кулланма). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы рөхсәте белән басыла”. – К., ,,Мәгариф” нәшрияты, 2007, 120б.

## Укыту предметына гомуми аңлатма.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”. Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Татар теле укытуның максатлары:

- Укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;
- Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә ирекле куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен белдерү;
- Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрлеләндерү;
- Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.

Татар теле укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларның логик фикеләү сәләтләрен үстерү.
6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел һәм әдәбият темаларын берләштерелеп төзелде, чөнки дәрес 2015-2016 нчы уку елына расланган укыту планында “Туган тел” буларак бирелә.

6 нчы сыйныф укучыларының тел осталыклары һәм күнекмәләре

6 нчы сыйныфта бирелә торган осталык һәм күнекмәләр (1-5 сыйныфларда алган белемнәргә өстәп күрсәтелә, ә кайберләре киңәйтелгән күләмдә санап китерелә):

- сүз төркемнәрен һәм аларның үзенчәлекле грамматик билгеләрен тану, мисалларны морфологик һәм өлешчә синтаксик яктан тикшерү;
- теоретик материалларга туры килә торган орфограммаларны мисаллар эченнән табу, сүзләрнең дөрес язылышын дәлилләү, сөйләмдә ярдәмче һәм синоним сүзләрне дөрес куллану, алынма сүзләргә төрләндергеч кушымчалар дөрес ялгау, алмашлыклардан һәм теркәгечләрдән фразаара бәйдәнеш чаралары буларак оста файдалану. Текст эчендә цифраларны дөрес язу;
- катлаулы план төзү. План нигезендә сочинениегә материал туплау, аны билгеле бер эзлеклелеккә китерү;
- сөйләм төрләрен (сыйфатлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү) аеру, шуларга туры китереп, сочинениеләр язу, телдән, монологик һәм диалогик формаларда сөйләү;
- Текстның эчтәлеген төрлечә (төгәл, кыскартып яки киңәйтеп) сөйләү;
- берәр хәл яки вакыйга хакында мәкалә язу;
- изложение, сочинение һәм башка язмаларны камилләштерү (тулыландыру, редаксияләү);
- эш кәгазьләре төреннән расписка һәм акт язу.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Укыту планында 6 нчы сыйныфта татар теленнән атнага 1 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик планны “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы (татар балалары өчен): 1-11 сыйныфлар.”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010.) нигезләнеп төзедем. Программада 34 сәгать каралган.

# УКЫТУНЫҢ ГОМУМИ, ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Төп һәм (урта)гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларында татар теленә өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– Укучыларның коммуникатив компетенциясен(аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашукүнекмәләре булдыру;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– “Татар теле һәм әдәбияты” фәненәкарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыруһәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

## Укытуның шәхси нәтиҗәләре

Төп һәм урта (тулы) гомуми белем бирү баскычларын тәгәлләгәндә,укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

– шәхесара һәм мәдәният ара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

– “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”,төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

Укытуның метапредмет нәтиҗәләре

Төп һәм(урта) белем бирү баскычларындататар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (*танып-белү, регулятив, коммуникатив)*формалаштыругахезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алукүнекмәләре формалаша.

*Танып-белүнәтиҗәләре:*

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;

– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;

– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;

– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

*Регулятив нәтиҗәләр*:

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;

- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

*Коммуникатив*нәтиҗәләр:

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү

## Укыту предметының төп эчтәлеге

*Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:*

- ана теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләрен белү;
- телдән һәм язма сыйләм, диалог, монолог, аралашу ситуацияләрендә тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә (радио, телеведениедән һ.б.) хәбәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктацион)саклау һәм сөйләм әхлагы нормаларын үтәү;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- ана теленең грамматик категорияләрен белү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сүз, сүзтезмә, җөмләләрдәге хаталарны төзәтү;
- җөмләгә синтаксик анализ ясау;
- төрле сүзлекләрдән һәм белешмә характерындагы китаплардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан урынлы файдалану;
- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача, гади һәм кушма җөмләләр кулланып сөйли белү;
- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, сурәтләү яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерлзү;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- тормыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикереңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу
- текстның планын төзү ;
- тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү;
- ана теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар теле дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне ана теленең кеше һәм җәмгыять тормышында алып торган урынын аңлап куллана һәм бәяли белергә өйрәнү

- *Татар теле укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр:*

- 1. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
- 2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
- 3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
- 4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
- 5. Укучыларның логик фикеләү сәләтләрен үстерү.
- 6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

- Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.
- Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

- *5 нче сыйныф укучыларының тел осталыклары һәм күнекмәләре*

- 6 нчы сыйныфта бирелә торган осталык һәм күнекмәләр (1-5 сыйныфларда алган белемнәргә өстәп күрсәтелә, ә кайберләре киңәйтелгән күләмдә санап китерелә):
- - сүз төркемнәрен һәм аларның үзенчәлекле грамматик билгеләрен тану, мисалларны морфологик һәм өлешчә синтаксик яктан тикшерү;
- - теоретик материалларга туры килә торган орфограммаларны мисаллар эченнән табу, сүзләрнең дөрес язылышын дәлилләү, сөйләмдә ярдәмче һәм синоним сүзләрне дөрес куллану, алынма сүзләргә төрләндергеч кушымчалар дөрес ялгау, алмашлыклардан һәм теркәгечләрдән фразаара бәйдәнеш чаралары буларак оста файдалану. Текст эчендә цифраларны дөрес язу;
- - катлаулы план төзү. План нигезендә сочинениегә материал туплау, аны билгеле бер эзлеклелеккә китерү;
- - сөйләм төрләрен (сыйфатлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү) аеру, шуларга туры китереп, сочинениеләр язу, телдән, монологик һәм диалогик формаларда сөйләү;
- - Текстның эчтәлеген төрлечә (төгәл, кыскартып яки киңәйтеп) сөйләү;
- - берәр хәл яки вакыйга хакында мәкалә язу;
- - изложение, сочинение һәм башка язмаларны камилләштерү (тулыландыру, редаксияләү);
- - эш кәгазьләре төреннән расписка һәм акт язу.

*Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына әдәбият укытуның төп максаты һәм бурычлары*

- матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү;
- төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби теоретик төшенчәләрне белү;
- балаларны татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, теарты, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү;
- укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
- әдәби әсәрне уку һәм анализлау;
- халык тарихын, мирасын өйрәнү аша Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.

*Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы*

Әдәби әсәрләрне танып-белү буенча төп эшчәнлек. Татар әдәбиятының күренекле язучылары һәм шагыйрьләре, аларның әсәрләре турында мәгълүмат булдыру; төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку; сәнгатьле уку; шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү; әсәрләрне анализлау; план төзү һәм әсәрләр турында кыскача бәяләмә (отзыв) язу; татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып бәяләү, үз фикерен әйтә белү.

*5 нче сыйныфны тәмамлаган татар балалары үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр*

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
-җырлар һәм аларның төрләрен аера белү;
-хикәя,фантастик хикәяне аера белү;
-шигырь һәм поэманың үзенчәлекләрен белү;
-уңай герой,лирик герой төшенчәләрен аера белү;
-әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү;
-милли орнаментларны аера белү.

# Укыту предметының сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча планлаштырылган нәтиҗәләре

VI класста татар теленнән үзләштерелергә һәм камилләштерелергә тиешле гомумкүнекмәләр

| Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә | Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итә белү | Фикерләү белән бәйле күнекмәләр | Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше |
|---|---|---|---|
| 1. Уку мәсьәләләрен мөстәкыйль билгеләү.<br>2. Уку операцияләрен планлаштыру.<br>3. Белем алуның рациональ ысулларын сайлау.<br>4. Үз-үзеңә контроль ясауның төрле формаларын үзләштерү.<br>Мөстәкыйль белем алу буенча эш башлау. | 1. Дәреслек белән эш итә белү.<br>2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.<br>3. Төрле текстлар белән эш иткәндә сәнгатьлелекне саклый белү.<br>4. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку:<br><br>-уку елы башында — 75 сүз;<br>-уку елы ахырында — 85 сүз.<br><br>5. Сүзлекләрдән файдалана белү, белешмә әдәбият белән системалы | 1. Уку мәсьәләсен куя белү.<br>2. Танып белү активлыгын үстерү.<br>3. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.<br>4. Төшенчә, термин, кагыйдә, закончалыкларны аңлап кабул итү күнекмәсен камилләштерү.<br>5. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләрен камилләштерү.<br>6. Грамматик анализ төрләрен үзләштерү: | 1. Телдән сөйләм:<br>• кагыйдәләрне аңлап эзлекле сөйли белү күнекмәсе;<br>• сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе.<br>2. Язма сөйләм:<br>• күчереп язу;<br>• сүзлек диктанты — 18-25 сүз;<br>• контроль диктант — 55-65 сүз,<br>• катлаулы план буенча изложение язу:<br><br>-уку елы башында — 140-160 сүзле текст (язманың күләме — 85-95 сүз);<br>-уку елы ахырында — 160-190 сүзле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эшләү.<br>6. Китапханәдә систематик каталог белән эш итә белү.<br>7. Аудио-видео белән эш итә белү. | • мөстәкыйль сүз төркемнәренә морфологик анализ;<br>• ярдәмлек сүз төркемнәренә морфологик анализ.<br>7. Тикшеренү ысуллары:<br>• модельләштерү;<br>• охшатып эшләү. | текст (язманың күләме — 95-105 сүз);<br><br>• фикер йөртү элементлары кертеп, гади яки катлаулы план төзеп сочинение язу;<br>• эш кәгазьләре язу (хат, мәкалә). |

## Укыту предметының темаларга бүленеше

| Т/с | Бүлекләр һәм темалар | Сәгать саны | Материал һәм җиһазлау | Метод һәм алымнар | Махсус белем һәм күнекмәләр | Контроль төре | Өй эше | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | План буенча | Фактик |
| 1. | Б.с.үс. Туган тел турында әңгәмә. | 1 | Дәреслек 3-5б. Тел турында материаллар. | Монологик, диалогик сөйләм. | телдән, монологик һәм диалогик формаларда сөйләү;<br>- Текстның эчтәлеген төрлечә (төгәл, кыскартып яки киңәйтеп) сөйләү | Хикәя “Туган телем – иркә гөлем”. | Туган тел турында мәкальләр | 7.09. | |
| 2. | 5 нче класста үтелгәннәрне кабатлау. | 1 | Дәреслек 4-5б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Ясалышлары ягыннан сүзләрнең тамыр һәм ясалма сүзләргә бүленүе. Сүзләрнең ясалу ысуллары: кушымча ялгау юлы белән ясалган | | 11 нче күнегү | 08.09. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | сүзләр, кушма сүзләр, парлы сүзләр, тезмә сүзләр, кыскартылма сүзләр. | | | | |
| 3 | Морфология. Сүз төркемнәре турында төшенчә. | 1 | Дәреслек 10-11б. | Укытучы сүзе, әңгәмә. Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Чагыштыру, күнегүләр эшләү. | Сүз төркемнәре турында гомуми төшенчәне искә төшерү. Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре буенча бер төркемгә берләштерелә торган сүзләрне сүз төркемнәре дип атау. Телдә барлыгы 12 сүз төркеме булу. Аларның мөстәкыйль (исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре), бәйләгеч (бәйлек, теркәгеч), модаль (хәбәрлек сүз, ымлык, кисәкчә) сүз төркемнәренә бүленүе. | | 12 нче күнегү | 15.09. | |
| 4 | Исем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрнең ясалыш төрләре | 1 | Дәреслек 11-13б. | Яңа материалны аңлату.Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Исем − предметны һәм затларны белдерүче сүз төркеме. Исем сүз төркеменең сораулары. Бер төрдән булган предметлар, затлар өчен уртак исемнәрнең уртаклык исем, бер төрдән булган предмет һәм затларның берсенә генә бирелгән исемнең ялгызлык исем булуы. Ялгызлык, уртаклык исемнәр. Ясалышлары ягыннан исемнәрнең тамыр һәм ясалма булулары. Исемнәрнең сүз ясалышындагы барлык ысуллар: сүзгә сүз ясагыч кушымчалар ялгау, сүзләрне кушу, сүзләрнең аваз составын үзгәртү, мәгънәләрен үзгәртү, сүзне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү һәм сүзләрне кыскарту ысулы белән ясалулары. Фамилия ясаучы кушымчалар. | Сүзлек диктанты. (Ялгызлык, уртаклык исемнәр). | 22 нче күнегү | 22.09. | |
| 5 | Исемнәрнең берлек һәм күплек саны. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 1 | Дәреслек 21-23б. | Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Исемнәрнең күплек төренә *-лар, -ләр, -нар, -нәр* кушымчалары ялгану. Исемнәрнең 6 килеше булуы. Баш килешнең кушымчасыз, калган килешләрнең кыек килешләр дип аталуы. Килеш кушымчалары. Баш килештәге исемнәрнең төрле җөмлә кисәге була алуы. | | 35 нче күнегү | 29.09. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | *Б.с.үс. “Чәчкә ат туган ягым”* | 1 | | Иҗади эшләү. | Килеш белән төрләнгән ялгызлык исемнәрен кулланып язу. | | Хикәя язарга | 06.10. | |
| 7. | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. | 1 | Дәреслек 28-30б. | Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | Исемнәрнең предмет, затның башка бер предметка, затка караганлыгын тартым кушымчалары аша белдерүе. Тартым кушымчаларының предмет яки затның сөйләүчегә (*мин, без*), тыңлаучыга (*син, сез*) сөйләмдә катнашмаган затка яки предметка (*ул, алар*) караганлыгын белдерүе. | Диктант – 7 мин. | Таблиөаны ятларга | 13.10. | |
| 8. | Исемнәрнең җөмләдә кулланылышы. | 1 | Дәреслек 36-39б. | Яңа материалны аңлату, күнегүләр эшләү. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | | | Җөмләләр төзергә | 20.10. | |
| 9 | Исемнәрне гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Дәреслек 40-45б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | | | Тестка әзерләнергә | 27.10. | |
| 10 | М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Портреты. Шагыйрьнең китаплары | М.Җәлилнең Казандагы музей-фатирына виртуаль экскурсия: http://tatar.museum.ru/Jalil/jalil.htm | - өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;<br>- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;<br>- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;<br>- геройларга характеристика бирү;<br>- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;<br>- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку. | Тест | Бер шигырен ятларга | 10.11. | |
| 11 | *Контроль диктант.* | 1 | “Диктантлар җыентыгы” | Иҗади эшләү. | Орфографиянең кыен очракларын үзләштерүне тикшерү максатында. | | кабатларга | 17.11. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | А.Алишның тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Дәреслек-хрестоматия, портреты. | Шагыйрьнең тормыш юлы турында белешмә. | классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру; өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;<br>- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;<br>- геройларга характеристика бирү;<br>- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;<br>- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку | . | А.Алишның экиятләр китабыннан берәр экият укырга | 24.11. | |
| 13 | Сыйфат турында төшенчә. | 1 | Дәреслек 45-49б. | Яңа материалны аңлату. | Сыйфатны предметның билгесен белдереп, *нинди? кайсы? кайдагы?* сорауларына җавап бирүе. Аның исемне ачыклап килүе. Сыйфат ачыклаган исемнең сыйфатланмыш булуы. Сыйфатның җөмләдә күбрәк аергыч һәм хәбәр булып килүе. | Сүзлек диктанты. | 79 нчы күнегү | 1.12. | |
| 14 | Сыйфатларның ясалышы. | 1 | Дәреслек 54-58б. Таблица | Күнегүләр эшләү. | Сыйфатларның ясалышы буенча төрләре: тамыр, кушымча ялгау юлы белән ясалган сыйфатлар, кушма, парлы һәм тезмә сыйфатлар. Ясалма сыйфатларның күбрәк исем һәм фигыльләргә махсус кушымчалары ялганып ясалуы. Сыйфат ясагыч кушымчалар: *-лы*; *-ле*, *-сыз*, *-сез*, *-гы*, *-ге*, *-кы*, *-ке*; *-чан*, *-чән*, *-ык*, *-ек*, *-к*, *-ынкы*, *-енке*, *-ма*, *-мә*, *-гыч*, *-ген*, *-лык*, *-лек*. Гарәп-фарсы, рус һәм башка теллрдән алынган сүзләрдән ясалган сыйфатлар. | | 88 нче күнегү | 08.12. | |
| 15 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 1 | Дәреслек 58-64б. | Яңа материалны аңлату. | Татар телендә дүрт сыйфат дәрәҗәсе булуы. Гади дәрәҗәдәге сыйфатлар предметның гадәти (төп) билгесен белдерүе. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатларның бер предметтагы билгенең башка предметтагы билге белән чагыштырганда, я бераз | | 102 нче күнегү | 15.12. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | артыграк, я азрак булуын күрсәтүе (*-рак, -рәк* кушымчалары ялганып ясала). Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның бер предметтагы билгенең башка предметларга караганда күбрәк булуын белдерә. Артыклык дәрәҗәсенең сыйфатның бер иҗегенә җайлаштырылган көчәйткеч кисәкчәләр ярдәмендә; *иң, утә, җете, дөм* һәм башка кисәкчәләр белән; бер үк сыйфатны кабатлау аша ясалуы. Сыйфатның кимлек дәрәҗәсенең *-су, -ча, -сыл, -сел, -мса, -гылт, -гелт, -кылтым, -келтем, -елҗем* кебек кушымчалар ярдәмендә ясалуы. | | | | |
| 16 | Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы. | 1 | Дәреслек 65-67б. | Яңа материалны аңлату, күнегүләр эшләү. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | | | 113 нче күнегү | 22.12. | |
| 17 | Сыйфатларны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Дәреслек 71-78б. Таблица | Күнегүләр эшләү, чагыштыру. Грамматик анализ. | Сыйфатларга морфологик анализ ясый белү. Тема буенча үтелгәннәрне кабатлау. | | 71 нче бит, сораулага җавап бирергә | 29.12. | |
| 18 | Һ.Такташ.“Иптәшләр” шигыре. . | 1 | Тормыш юлы, плакат. Такташ турында истәлекләр | Һ.Такташ тормышындагы һәм иҗатындагы үзенчәлекләр белән танышу.Аның Тукай шигъриятендәге | классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру; Сүзлек өстендә эш.<br>- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;<br>- геройларга характеристика бирү;<br>- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен | Сорауларга җавап әзерләү. Такташ иҗаты буенча | “Иптәшләр” шигырен ятларга.. | 19.01. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | зур традицияләрне дәвам иттерүче новатор шагыйрь булуын аңлатырга. | ачыклау;<br>- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку | тест төзергә. | | | |
| 19 | Сан турында төшенчә.<br><br>Саннарның ясалышы. | 1 | Дәреслек 79-83б. Таблица | Яңа материалны аңлату, күнегүләр эшләү. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Предметның санын, исәбен белдереп, *ничә? күпме? никадәр? ничәнче? ничәләп? ничәү? ничәшәр?* сорауларының берсенә җавап булган сүз төркеменең сан дип аталуы. Җөмләдә санның күбрәк исемне ачыклап килүе, аергыч булуы. Сан белән ачыкланган сүзнең саналмыш булуы. Санның күбрәк цифрлар белән язып күрсәтелүе. Гарәп һәм рим цифрлары һәм аларны куллану. Ясалышлары буенча саннарның тамыр, кушма, парлы, тезмә төрләре булу, аларның дөрес язылышлары. | | 140 нчы күнегү | 26.01. | |
| 20 | Гарәп һәм рим цифрларының язылышы. | 1 | Дәреслек 86-88б. | Укытучы сүзе, әңгәмә. | | | 144 нчы күнегү | 02.02. | |
| 21 | Сан төркемчәләре. | 1 | Дәреслек 88-93б. Таблица | Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Белдергән мәгънә төсмерләренә һәм формаларына карап, саннарның биш (микъдар, тәртип, бүлем, чама, җыю) төркемгә бүленүе. Микъдар саннарның предметларның төгәл исәбен белдерүе һәм *ничә? күпме? никадәр?* сорауларына җавап булуы. Өлеш саннарының да шушы төркемгә керүләре.<br>Тәртип санының предметларның саналу яки урнашу тәртибен белдереп, *ничәнче?* соравына җавап булуы. Микъдар санына -*нчы*, -*нче*, -*ынчы*, -*енче* кушымчалары | | 156 нчы күнегү | 09.02. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | кушылып ясалуы.<br>Бүлем санының предметны тигез өлешләргә бүлүен белдереп, *ничәшәр? күпмешәр?* сорауларына җавап бирүе. Микъдар санына -*ар*, -*әр*, -*шар*, -*шәр* кушымчалары ялганып ясалуы<br><br>Чама санының предмет санын якынча белдерүе, *никадәр? ничәләп?* сорауларына җавап бирүе. Төп санга -*лап*, -*ләп*, -*ларча*, -*ләрчә*, -*нарча*, -*нәрчә* кушымчалары ялгап ясалуы. | | | | |
| 22 | Саннарның җөмләдә кулланылышы. | 1 | Дәреслек 100-102б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Саналмышы белән килгән саннарның җөмләдә күбрәк аергыч булулары, төрләнмәве. Саналмышыннан башка килгән саннарның, исемнәр кебек, килеш һәм тартым белән төрләнүе, җөмләнең төрле кисәкләре булып килүләре. Математик гамәлләрдә кулланыла торган саннарның саналмышсыз килеп төрләнә алуы һәм җөмләнең төрле кисәге булуы. | | 175 нче күнегү | 16.02. | |
| 23 | Саннарны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Дәреслек 102-106б. Таблица | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | Саннарга морфологик анализ ясый белү. | | 176 нчы күнегү | 02.03. | |
| 24 | *Диктант.* | 1 | “Диктантлар җыентыгы” | | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү. | | | 09.03. | |
| 25 | И.Гази. “Йолдызлы малай” хикәясе. | 1 | Дәреслек-хрестоматия. Портреты. | Әсәрне сәнгатьле уку. Темасын һәм исемен ачыклау. Әсәрдәге геройның дошманга булган | Сүзлек өстендә эш.<br>классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру; | . | Илгизәрнең батырлыгы турында | 16.03. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | нәфрәтен күрсәтү,эчке дөньясын ачу. | | | сөйләрг ә | | |
| 26 | Рәвеш. Рәвеш турында төшенчә. Рәвешләрнең ясалышы. | 1 | Дәреслек 106-109б. Таблица | Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Җөмләдә эш яки хәлнең билгесен белдереп, *ничек? кая? кайда? кайдан? күпме? никадәр?* кебек сорауларның берсенә җавап бирә торган сүз төркеменең рәвеш дип аталуы. Рәвешнең җөмләдә күбрәк фигыльне, сирәгрәк сыйфатны һәм рәвешне ачыклап килүе, хәл кисәк булуы. Рәвешнең төрләнми торган сүз төркеме булуы.<br>Төзелеше ягыннан рәвешләрнең 5 төргә: тамыр, кушымчалар ялгау юлы белән ясалган, кушма, парлы, тезмә рәвешләргә бүленүе. Кушма рәвешләрнең кушылып, парлы рәвешләрнең сызыкча аша, тезмә рәвешләрнең составындагы сүзләрнең аерым язылуы | | 187 нче күнегү | 23.03. | |
| 27 | Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре. | 1 | Дәреслек 114-115б. | Яңа материалны аңлату. | Мәгънәләре ягыннан рәвешләрнең 6 төркемчәгә: саф, охшату-чагыштыру, күләм-чама, вакыт, урын һәм сәбәп-максат рәвешләргә бүленүе. Саф рәвешләрнең эшнең сыйфатын белдерүләре, *ничек? ни рәвешле?* сорауларына җавап булулары.<br>Күләм-чама рәвешләренең эш яки билгенең күләм-чамасын белдерүләре, *күпме? ничаклы? никадәр? нихәтле?* сорауларына җавап бирүләре.<br>Охшату-чагыштыру рәвешләренең эшнең үтәлү ысулын белдерүләре, *ни төсле?* соравына җавап булулары.<br>Вакыт һәм урын рәвешләренең эшнең үтәлү урынын һәм вакытын белдерүләре, *кайчан?* | | 196 нчы күнегү | 06.04. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | (вакыт рәвеше), *кайда? кая? кайдан?* (урын рәвешләре) сорауларына җавап бирүләре Сәбәп-максат рәвешләренең эшнең сәбәбен, максатын белдерүләре, *ник? нишләп? нигә? нилектән?* сорауларына җавап бирүләре | | | | |
| 28 | С.Хәким. “Бакчачылар” поэмасы. | 1 | Дәреслек-хрестоматия. Портреты. | Поэманы аңлатмалы уку.Эчтәлекне үзләштерү.Хезмәт кешесенә ихтирам тәрбияләү. | - өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;<br>- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;<br>- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;<br>- геройларга характеристика бирү;<br>- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;<br>- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку | . | Һөнәр һәм хезмәт турында мәкаль әйтемнәр язып килергә | 13.04. | |
| 29 | Рәвешләргә морфологик һәм морфологик-синтаксик анализ. | 1 | Дәреслек 127-129б. | Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | Тема буенча үтелгәннәрне камилләштерү күнегүләре. Рәвешләргә морфологик анализ ясый белү. | | 222нче күнегү | 20.04. | |
| 30 | Р.Фәйзуллин. “Күмәч пешерүчеләр җыры” шигыре. Шәүкәт Галиев. “Саумысыз, арышларым” шигыре | 1 | Иген үстерүчеләр һәм ипи пешерүчеләр сурәтләнгән картиналар. Икмәк турында җырлар, шигырьләр. | “Күмәч пешерүчеләр җыры” шигырен өйрәнү, икмәккә ихтирам, хезмәт кешесенә карата хөрмәт тәрбияләү. | - өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;<br>- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;<br>- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;<br>- геройларга характеристика бирү;<br>- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;<br>- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку | | Шигырьнең бер строфасын ятларга | 27.04. | |
| 31 | Алмашлык | 1 | Дәреслек 137- | Яңа материалны | Үзләрен атамыйча гына зат яки предметларга, | | 243 нче | 04.05. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | турында төшенчә. Алмашлыкларның ясалышы. | | 139б. | аңлату.Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | аларның билгесе яки санына һәм хәлләренә күрсәтә торган сүзнең төркеменең алмашлык дип аталуы. Алмашлыкларның җөмләнең теләсә кайсы кисәге булып килә алуы. | | күнегү | | |
| 32 | Алмашлык төркемчәләре. | 1 | Дәреслек 142-144б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Мәгънәләре буенча алмашлыкларның җиде төркемгә бүленүе: зат алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары, сорау алмашлыклары, юклык алмашлыклары, билгесезлек алмашлыклары, тартым алмашлыклары. | | 293 нче күнегү | 11.05. | |
| 33 | Алмашлыкларны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | Дәреслек 170-178б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | Үзләре күрсәткән сүзләр җөмләнең кайсы кисәкләре булса, алмашлыкларның да шул ук кисәкләр булып килүе. Алмашлыкларга морфологик анализ ясый белү. | | 296 нчы күнегү | 18.05. | |
| 34 | Йомгаклау дәресе | 1 | | | Җәйге каникулга укучыларга укыласы әсәрләр исемлеге белән таныштыру. | | Әсәрләр исемлеген бирү | 25.05. | |

## Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү

Укыту – методик комплекты

1. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010.)
2. Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты.(Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М.,Хаков В.Х., Измайлова Г.Г., Хәмидуллина Э.Х.Казан, 2005.)
3. 6 нчы сыйныфта татар теле дәреслеге.
4. Татар теле морфологиясе. /Ф.М. Хисамова. - Казан, “Мәгариф” , 2005.
5. Хәзерге татар әдәби теле. / Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев.- Казан, “Мәгариф” , 1994.
6. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. / Ф.С.Вәлиева, Г.Ф. Саттаров. – Казан: “Раннур”, 2000.
7. Татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com).

# Гомумбелем күнекмәләрен бәяләүнең критерийлары һәм нормалары

<u>Язма эшләрнең күләме һәм аларны бәяләү:</u>
Сүзлек диктанты –18-25 сүз
Сүзлек диктантын бәяләү

1. Пөхтә язылган, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела.
2. Бер орфографик хаталы эшкә “4” ле куела.
3. Өч орфографик хаталы эшкә “3” ле куела.
4. Биш орфографик хаталы эшкә “2” ле куела.

Контроль диктант- ел башында 55-65 сүз, ел ахырында 60-70 сүз
Контроль диктантны бәяләү:

1. Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаган эшкә “5” ле куела. (Бер – орфографик, ике пунктуацион хата булырга мөмкин.)
2. Ике орфографик, ике пунктуацион яки бер орфографик, дүрт пунктуацион хаталы эшкә “4” куела.
3. Дүрт орфографик, дүрт пунктуацион яки өч орфографик, алты пунктуацион хаталы эшкә “3” куела.
4. Алты орфографик, биш пунктуацион яки биш орфографик, сигез пунктуацион хаталы эшкә “2” куела.

Изложение текстының күләме
ел башында 140-160 сүз (85-95 –язма күләме)
ел ахырында 160-190 сүз (95-105- язма күләме)

Изложениене бәяләү

1. Тема тулысынча ачылган, фактик һәм техник хаталары булмаган, стиль бердәмлеге саклангaн эшкә «5» ле куела. (Бер орфографик, ике пунктуацион яки ике грамматик хатасы булырга мөмкин.)

2. Текстның эчтәлеге темага нигездә туры килсә, фикерне белдерүдә зур булмаган ялгышлыклар җибәрелсә, бер-ике фактик, бер-ике техник хатасы булса, ике орфографик, ике-өч пунктуацион, бер грамматик хатасы булган эшкә «4» ле куела.
3. Язмада эчтәлек эзлекле бирелмәсә, стиль бердәмлеге сакланмаса, өч фактик, ике-өч техник хатасы булса, өч орфографик, дүрт пунктуацион, ике грамматик хатасы булган эшкә «3» ле куела.
4. Эзлеклелек, стиль бердәмлеге сакланмаса, язма эш планга туры килмәсә, фактик һәм техник хаталары күп булса, орфографик хаталарның саны дүрттән, пунктуацион хаталарның саны биштән, грамматик хаталар саны өчтән артса, «2» ле куела. Сочинениенең күләме һәм аны бәяләү

Иҗади эшнең бер төре буларак, сочинение — укучының язма рәвештә үти торган эше. Ул бәйләнешле сөйләм үстерү күнекмәләре булдыруда зур әһәмияткә ия. Әдәби (хикәяләү, очерк, истәлек, хат, рецензия һ. б.), әдәби- иҗади, өйрәтү характерындагы, ирекле, рәсемнәр нигезендә үткәрелә торган һәм контроль сочинениеләр була.

Сочинениене бәяләү

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Зат алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 145-149б. | Яңа материалны аңлату. | I һәм II зат алмашлыклары сөйләмдә катнашкан затларны белдерә, берлек һәм күплек санда киләләр, килеш белән төрләнәләр, III зат алмашлыклары *ул, алар* сөйләмдә катнашмаган, әмма шулар турында сүз барган зат яки предметларны белдерәләр, берлек яки күплек санда киләләр. Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнүе. |
| Тартым алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 149-153б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Предметның кайсы затка каравын белдергән алмашлыкларның тартым алмашлыклары дип аталулары. Алар кайбер алмашлыкларга *-ныкы, -неке* кушымчалары ялганып ясала. |
| Күрсәтү алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 153-155б. | Яңа материалны аңлату. | Күрсәтү алмашлыкларының затка, предметка һәм шулай ук предмет яки эш-хәл билгеләренә күрсәтүе. Күрсәтү алмашлыкларының килешләр белән төрләнүе. |
| Күрсәтү алмашлыкларының тартым, килеш белән төрләнеше. | 1 | Дәреслек 155-157б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | |
| Сорау алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 158-160б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | Сорау алмашлыкларының сорау формасында зат яки предметларга, аларның билгесе яки саннарына һәм хәлләренә күрсәтүе. Юклык алмашлыкларының предметны, билгене кире кагуны яки аларның булмавын белдерүләре. Аларның сорау алмашлыклары алдына *һич* яки *бер* сүзләрен кую юлы белән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ясалулары. |
| Билгеләү алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 160-161б. | Яңа материалны аңлату. | Билгеләү алмашлыкларының гадәттә затларны, предметларны гомумиләштереп белдерүләре. Аларның исемне ачыклап аергыч булып килгәндә төрләнмәүләре. |
| Билгеләү алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. | 1 | Дәреслек 161-164б. | Яңа материалны аңлату. Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. Грамматик анализ. | Үзләре ачыклаган сүз урынына килгәндә килеш, тартым белән төрләнүе, берлектә һәм күплектә килүләре. Үз алмашлыгының өч затка да каравы һәм тартым, килеш белән төрләнүе, берлектә һәм күплектә килүе. |
| Билгесезлек алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 164-168б. | Яңа материалны аңлату. | Билгесезлек алмашлыкларының сорау алмашлыкларына *әллә* сүзе яки -*дыр*, -*дер*, -*тыр*, -*тер* кисәкчәләре кушылып ясалулары. |
| Юклык алмашлыклары. | 1 | Дәреслек 168-170б. | Дәреслек һәм башка чыганаклар белән эшләү. | |